ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

15.12.2023 г. Казань № 701-6/соц-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1538 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2023 елның 15 декабрендәге 59-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын гамәлдән чыккан дип таныргa:

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре гомуми белем бирү мәктәпләрендә гомуми туклану предприятиеләрендә сатыла торган продукциягә (товарларга) иң югары бәяләрне билгеләү турында» 09.09.2011 № 8-19/соц;

«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү мәктәпләрендә гомуми туклану предприятиеләрендә сатыла торган продукциягә (товарларга) иң югары бәяләрне билгеләү турында» 10.12.2015 № 8-3/соц.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев